КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 июль г.Казань № 801

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 29 март, 161 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 25 июль, 579 нчы; 2014 ел, 21 июль, 520 нче; 2015 ел, 1 июнь, 393 нче; 2018 ел, 14 июнь, 480 нче; 2018 ел, 29 сентябрь, 887 нче; 2020 ел, 30 октябрь, 973 нче; 2023 ел, 30 март, 378 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекнең өченче абзацында «министрлыкларга, дәүләт комитетларына һәм ведомстволарга» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлектә:

беренче абзацта «министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Министрлык, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «Татарстанстат» сүзен «Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацта «Татарстанстат тарафыннан» сүзләрен «Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

егерме беренче абзацта «министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар» сүзләрен төшереп калдырырга;

егерме өченче абзацта «министрлыкларга, дәүләт комитетларына һәм ведомстволарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 август, 690 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 6 октябрь, 952 нче; 2022 ел, 15 гыйнвар, 16 нчы; 2022 ел, 20 июль, 698 нче; 2022 ел, 18 ноябрь, 1231 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучылар чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

6 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон формада бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча

тәкъдим (заявка) бирү планлаштырыла торган айның 1нче көненә бирелгән салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турында салым органының белешмә кәгазе.»;

13 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

14 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин